КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь | г.Казань | № 1125

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Костер» республика балалар савыктыру-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе исемен «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе итеп үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Костер» республика балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагына тапшыру турында» 2020 ел, 19 май, 404 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Костер» республика балалар савыктыру-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе исемен «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Учреждение) итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына 60 көн эчендә Учреждение уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм аны законнар белән билгеләнгән тәртиптә яңа редакциядә теркәүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Костер» республика балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы карамагына

тапшыру турында» 2020 ел, 19 май, 404 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Костер» республика балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен» сүзләрен «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Костер» республика балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесен» сүзләренең «Костер» республика яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең» сүзләренә алмаштырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин